Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
«Сөйки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАРЫ

2021 елның 31 маендагы № 24

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Сөйки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының ««Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексы турында яңа редакциядә» 2012 елның 15 маендагы 55 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Кама Тамагы районы прокуратурасының 2021 елның 19 маендагы 02-08-02-21 номерлы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 26 статьясына үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Сөйки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы Законының 26 статьясына үзгәреш кертү турында» 2013 елның 17 июлендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Сөйки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Сөйки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2012 елның 15 маендагы 55нче номерлы карары белән расланган Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексына, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы, Кызыл Армия урамы, Авыл үзәге;

- Кама Тамагы районы Сөйки авылы, Колхоз йорты 16а, китапханә бинасы,

шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Сөйки авыл җирлеге башлыгы,
муниципаль берәмлек Советы рәисе
«Сөйки авыл җирлеге»
Кама Тамагы муниципаль районы В.П. Никитин